КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1087

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 апрель, 281 нче; 2018 ел, 14 июнь, 481 нче; 2018 ел, 17 октябрь, 940 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1320 нче; 2020 ел, 6 август, 658 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исеменә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «11 163,0» саннарын «11 498,0» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта:

икенче абзацка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларында:

исеменә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацына «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

II бүлекнең исеменә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

4 пунктка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

5 пунктка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ һәм $8^2$ пунктлар өстәргә:

«$8^1$. Муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләре урынбасарларына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме тиешле муниципаль берәмлекләрнең контроль-счет органнары рәисләренә акчалата түләүләрнең 0,8 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

$8^2$. Муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары аудиторларына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме тиешле муниципаль берәмлекләрнең контроль-счет органнары рәисләренә акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

10 пунктка «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның 6 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфалары белән чагыштырганда югарырак төркеменә караган вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул били торган вазыйфага караган вазыйфалар төркеме өчен беренче классլы чин биргәнгә кадәр класслы чин өчен аның оклад күләмен исәпләп чыгару вазыйфаи окладның 3 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

Әгәр дә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфалары белән чагыштырганда түбәнрәк төркеменә караган вазыйфасына билгеләнсә һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класслы чик бирелсә, класслы

чин өчен оклад күләмен исәпләп чыгару вазыйфаи окладның 7 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла;»;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтада:

«Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, тикшерү органы аудиторы» юлының 1 графасында «тикшерү органы аудиторы» сүзләрен төшереп калдырырга;

астөшермәгә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымтада:

«Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, тикшерү органы аудиторы» юлының 1 графасында «тикшерү органы аудиторы» сүзләрен төшереп калдырырга;

астөшермәгә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән 3 нче кушымтаның астөшермәсенә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән 4 нче кушымтаның астөшермәсенә «рәисләренең» сүзеннән соң «, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән 5 һәм 6 нчы кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәдәге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлау органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 ел, 6 август, 658 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

бу карарның гамәле 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә (бу карарда гамәле 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 1 пунктның унсигезенче – егерменче абзацыннан тыш) кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 ноябрь, 1087 нче
карары редакциясендә)

## Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(сум)

| Вазыйфа исеме | Беренче төркем* | Икенче төркем* | Өченче төркем* | Дүртенче төркем* | Сигезенче төркем* |
|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 41 942 | 38 010 | 34 967 | 31 966 | 30 442 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 37 748 | 34 209 | 31 469 | 28 767 | 27 398 |
| Депутат | 18 958 | 18 140 | 17 084 | 15 492 | 14 927 |
| Җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы | 16 111 | 15 420 | 14 517 | 13 166 | 12 684 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 37 748 | 34 209 | 31 469 | 28 767 | 27 398 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 35 414 | 31 735 | 28 286 | 25 871 | 24 606 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 28 516 | 25 411 | 23 686 | 20 927 | 20 927 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 ноябрь, 1087 нче
карары редакциясендә)

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | республика һәм район әһәмиятендәге шәһәрләр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләрендә | | | | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрендә һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
| | дүртенче төркем* | бишенче төркем* | алтынчы төркем* | җиденче төркем* | тугызынчы төркем* | унынчы төркем* | унберенче төркем* | уникенче төркем* |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 966 | 29 005 | 27 301 | 24 381 | 21 394 | 18 748 | 17 253 | 15 759 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 28 765 | 26 103 | 24 567 | 21 803 | 17 062 | 13 968 | 12 398 | 11 499 |
| Депутат | 15 492 | 13 899 | 12 966 | 12 348 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 |
| Җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы | 13 166 | 11 813 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.